# Сөнгатуллина Венера Зәки кызы



**Сөнгатуллина Венера Зәки кызы** 1946 нчы елың 4 нче гыйнварендә Мөслим районы Метрәй авылында дөньяга килгән.

1-8 нче сыйныфларны Метерәй авылында, 9-11 нче сыйныфларны Мөслим урта мәктәбендә тәмамлап, 1965-1970 нче елларда Алабуга дәүләт педагогия институтының математика-физика факультетына укырга керә.

1970-1975 нче елларда Мәллә тамак урта мәктәбенә математика укытучысы булып эшкә кайта.

1976 нчы елны Мөслимдә кичке мәктәптә укыта башлый.

1979-2001нчы елга кадәр Мөслим урта мәктәбендә (хәзерге Тукай мәктәбендә, хәзерге Мөслим лицеена күчеп дәвам итә ) математика дәресләрен укыта. Эшләү дәверендә 30 га якын медалист чыгара.

Венера Зәкиевна берсеннән-берсе тырыш 3 кыз тәрбияләп үстерә. Олы кызы Эльвира Мансуровна Г.Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбендә инглиз теле укыта. Икенче кызы Лилия- КГУ да журналист белемен алып, берничә шәхси газета нәшер итүче. Өченче кызы-Алсу Казан педагогия институтын тәмамлап, “Язмыш кочагы”,”Адашкан мәхәббәт”, “Безнең авыл гыйбрәте” газеталарының баш мөхәррире. Хәзерге көндә Лилия белән Алсу бергәләп берничә газета чыгаралар.

“Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесе белән бүләкләнгән Венера Зәкиевна яшәү мәгънәсенең җимешләрен татый. Уңган булган кыз-кияүләренең 7 оныгының игътибарын, ярату һәм ихтирамын тоеп, балаларының уңышларына сөенеп,бәхетле әни, бәхетле дәү әни булып яши ул бүгенге көндә.